ГЛАВА
БУТЛЕРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БУТЛЕРОВКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2020 №5

с.Мокрые Курнали

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлегенең Ивановский поселогында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2020 елның 12 ноябренә 12 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлегенең Ивановский поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Бутлеровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- Үзәк урам буенча юлга вак таш җәю (килешү буенча эшләр өчен түләү),
- урамнарны карап тоту һәм төзекләндерү (кардан чистарту, урамнарны чабу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

ӘЙЕ ЮК».

2. Гражданнар жыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан авыл клубы бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Ивановский поселогы, Үзәк ур., 17 й.

Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы** **И.Л.Хушанова**

СОВЕТ БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ